№ 26 (1153), 23 июнь 2012 ел



### Уразаның кыймммәте

Коръән-Кәримдәге аятьләрдән күренгәнчә, Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә уразаны безгә кадәр булган кавемнәргә дә фарыз кылган, башка пәйгамбәрләрнең өммәтләре дә ураза тоткан. Ураза мөэминнәр өчен ел буена көтеп алынган кадерле, бәрәкәтле ай. Бу айда иман әһелләре Раббысына ихласлык белән күп гыйбадәтләр кыла, Аңа якыная, барлык гөнаһларының гафу ителүенә ирешә. Шуңа да бу мөбарәк айга күп төрле исемнәр бирелгән: рәхмәт ае, ярлыкау ае, сабырлык ае, котылу ае, әҗер бирелү ае, игелек кылу ае, гыйбадәтне аеруча күп кылу ае, ураза ае, Аллаһы мәрхәмәтлелеге ае, изгелекләр ае, Коръән иңгән ай, шәрифле ай, нурлы ай...

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу айны көтеп, әзерләнеп алырга кушкан. Рәҗәб ае тугач та, ул шундый догалар кылган: *«Йә Аллаһым, безгә Рәҗәбне, Шәгъбанны бәрәкәтле кыл, Рамазан аена ирешергә насыйп әйлә»*. Шуның өчен безгә дә Рамазан аеның тулы савапларына ирешергә насыйп итүне Раббыбыздан даими догалар кылып сорау тиешле гамәлләрдән санала.

Сөекле Рәсүлебез Рамазан аена кергәнче, Шәгъбан аенда унбишәр көнгә чаклы ураза тота торган булган. Гайшә анабыздан килгән хәдистә болай диелә: *«Пәйгамбәрнең Рамазаннан башка айда тулысынча ураза тотканын күрмәдем, Шәгъбан аенда ул Рамазаннан кала иң күп уразаны тота иде»*.

Димәк, Пәйгамбәребез үрнәгендә Шәгъбан аенда мөмкин кадәр берничә көн ураза тотып, күп догалар кылып, Рамазанны көтеп алсак, бу, инша Аллаһы, Рамазан уразасының ләззәтен тагын да ныграк сизәргә ярдәм итәчәк. Рамазан аенда кылган гамәлләргә әҗер-саваплар бермә-бер арта. Бер фарыз гамәлгә саваплар җитмеш тапкырга артса, нәфел гыйбадәтләре өчен фарыз гамәлләр кебек әҗер-саваплар язылачак. Айның тәүге ун көне - рәхмәт көннәре, уртадагы ун көне - гафу-мәгъфирәт, ягъни ярлыкау көннәре, ахыргы ун көн - уттан котылу көннәре, дип исәпләнә.

*("Дин вә йола" газетасыннан)*

# Яман сүзләрдән тыелабызмы?

Яман сүз белән кычкырып (кеше ишетерлек итеп) сөйләүне Аллаһы сөймидер. Мәгәр берәү хаксыз золым кылынса, ягъни җәберләнүче чарасыз булып залимга каршы яман сүз әйтсә, гөнаһ булмас. *«Аллаһы сүзләрне ишетүче, күңелдәгеләрне белүче»* («ән-Ниса» сүрәсе, 148 нче аять).

*«Әшәке сүз әйтү, сүгенү – кешенең оятсыз әйберләр турында ачыктан-ачык сөйләве»*, – дип җиткергән имам-әл-Газали.

Бу аятьне укыгач та: «Әгәр мине начар сүзләр белән кимсетсәләр, мин дә аңа шундый сүзләр белән җавап кайтара алам икән», – дип аңларга мөмкин. Тик бу һич тә алай түгел икән. Коръәннең танылган тәфсирчеләре шулай аңлата: ул (шундый) сүзләр белән җавап бирү – син үзеңне җәберләүләрен (сүзләр белән) кемгәдер исбатларга тырышканда гына кабатларга рөхсәт ителә икән. Без еш кына: «Хәзерге яшьләр бик бозык, алар теләсә нәрсә әйтеп сүгенәләр, теләсә нәрсә эшлиләр, теләсә кайда үзләренең хаҗәтләрен башкаралар», – дип әйтергә яратабыз. Мин үзем дә шундыйрак фикердә идем. Бу мәсьәләдә мин, кызганычка, күпкә ялгышмаганмындыр. Тик үземнең замандашлар, яшьтәшләр турында кирәгеннән артык яхшы фикердә булганмын икән.

Язмышым язылган буенча миңа Чаллыда күземә операция ясатып (20 көн эчендә бер күзгә 2 мәртәбә) һәм Казанда нурлар белән дәвалану булегендә дә айлар буе ятарга туры килде. Менә мин шунда аралашкан кешеләрнең күпчелеге (анда булган барлык милләт кешеләре дә), бик күп кенә түбәтәйлеләр дә һәм үзләренең намаз укый башлаулары белән мактанып алырга яратучылар да – барысы да диярлек, гадәти сүзләр сөйләп торганда да, бик мулдан сүгенү сүзләре дә кулланалар. Аеруча шунда дәваланучы яки безне дәвалауга катнашы булган хатын-кызларга мондый сүзләрне һич тә кызганмыйлар. Без яшьләрне, хәтта сабый балаларны да бик тырышып оятсыз сүзләргә үзебез өйрәтәбез икән бит. Хәзерге заман телефоннарыннан аралашканда (үзенең хатынымы, баласы яки оныгымы, әби-бабасымы, әлләә гадәти танышымы), әгәр 20 минут сөйләшсәк, һич ачуыбыз да килмәгән очракта да бер 10 минутлап сүгенеп үткәрәбез. Аларның хәлләрен белгәндә яки үзебезнең хәлне аңлатканда без сөйләшү бәясен генә дә ике мәртәбә артыграк түләгән булабыз түгелме?

Ә хатыныбыз, бала-оныкларыбыз, безнең әле гомеребез булса, шундый ук сүзләр белән «иркәләмәсләр», дип кайсыбыз әйтә ала. Дөрес, инде яшь кенә хатыннар һәм кызлар да (кайберләре дип әйтик) ирләрдән калышмаска тырышалар.

Яман сүзләр безнең тормышта сүгенүдән башка да җитәрлек. Моның иң киң таралганы, мөгаен, гайбәттер. Кемнәрне ничек кенә итеп тикшермибез без. Ә үзебезнең хәл турында уйлап та бирмибез. Без гайбәтләренә кергән кешеләр безгә караганда тәртиплерәк тә, әдәплерәк тә, гаделрәк тә булырга бик мөмкин бит. Гайбәт – ул кеше үзе безнең янда булмаганда аның турында ул кешегә ошамастай (ул сүзләр дөрес булса да) сүзләр сөйләү. Ислам динендә гайбәт үзеңнең үлеп ятучы туганыңның итен ашауга тиңләнә.

Безнең арадагы байтак кына кешеләр үзләренең төннәр буе эчеп утырулары, хатыннар белән зина кылулары һәм башка шундый гамәлләре белән бик горурланып мактаналар. Мондый вакытларда аларның күңелләре күтәрелеп, яшәү дәртләре арта төсле. Бу мәсьәләдә Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: *«Кешеләр төнлә (кеше күрмәгәндә) кылган зур гамәлләре, гөнаһлары турында көндез башкаларга сөйләсәләр, үзләренә тагын шундый ук күләмдә гөнаһ өстиләр»*, – ди. Болар башкаларны да шундый гамәлләр эшләргә һәм алар белән мактанырга өйрәтә, үрнәк күрсәтәләр булып чыга. Әгәр мондыйлар башкаларны начар гамәлләр кылырга өйрәтеп калдырып, үзләре үлеп китсәләр, «шәкертләре» кылган гамәлләрдән әлеге әрвахларга да өлешләр барып торачак.

Төрле ялган хәбәрләр таратучылар да яман хәбәрчеләрдән. Бәлки, аларга бу сүзләре әле бүген баю мөмкинлеге бирсә дә. Мәсәлән, бер елны язга таба тоз бетәчәге турында хәбәр таралып, сатуда тозның бәясе берничә мәртәбә артып кына калмады, хәтта тоз бетеп тә торды. Андый хәлләрне карабодай ярмасыннан башлап, байтак әйберләргә карата әйтеп була. Кешеләрне алдап, куркытып җыелган акчадан нинди файда килер? Аллаһы каршында җавап та бирәсе бар бит әле. Пәйгамбәребез: *«Кыямәт көнендә Аллаһыга ышанучының яхшылыгы үлчәвендә иң авыры булыр, Аллаһы һич кенә дә начар сүзләр сөйләүче һәм таратучыларны яратмый»*, – ди.

**Әхнәф АБДУЛЛИН.**
*("Дин вә йола" газетасыннан)*



# Мәетләргә ризык

Үлгәннәр, мәет булуга карамастан, ризыкка мохтаҗлар. Әмма мәеткә карата «ризык» дигән сүзнең эчтәлеге башка мәгънәгә ия була. Мәеткә карата ризык, азык дигәне игелекле, изге, яхшы эш эшләп, шул эшне эшләүдән килеп чыккан игелек, савап, әҗерне үлгән кешегә бүләк итү белән бәйле. Бу бүләкләр үлгән кешегә ирешә, аны тукландыра, аңа тынычлык, рәхәтлек биреп тора. Дөньялыкта без ризыкның төрлесен ашыйбыз, кулланабыз. Без, тереләр, мәетләргә ризыкның кайсы төрләрен җиткерә алабыз икән?

— Кем дә кем «Йәсин» сүрәсен Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы өчен укыса, аның алдагы гөнаһлары кичерелер. «Йәсин»не, шулай булгач, мәетләрегезгә укыгыз (хәдис-шәриф).

– Кем дә кем «Йәсин»не каберстанда укыса, ул каберстандагы мәетләр 40 көн газап тоймаслар. Укучы кеше исә каберстанда булган мәетләр санынча савап алыр (хәдис-шәриф).

Хәзрәти Әбү Мәлик ибне Динар радыйаллаһу ганһе җомга көнне каберстанга юл тота, анда ул нур күрә. Кинәт бер тавыш: «Йә Әбү Мәлик ибне Динар! Бу нур мөселманнарның мәетләргә җибәргән бүләкләре була!» – ди. Хәйран калган Әбү Мәлик: «Нинди бүләк ул?» – дип тавыштан сорый. Тавыш: «Иман әһеле тәһарәт алып, 2 рәкәгать намаз укыса һәм 1нче рәкәгатьтә «Әлхәмд»тән соң «әл-Кәфирун», 2нче рәкәгатьтә «Әлхәмд»тән соң «әл-Ихлас» сүрәсен укып, намазының әҗерен мәетләргә, әрвахларга багышласа, Аллаһы Тәгалә бу багышлаган савапларны нур кыяфәтендә мәетләргә җиткерә, һәм алар ята торган каберләрне киңәйтеп җибәрә», – ди Әбү Мәликкә. Шул заманнан бирле Әбү Мәлик җомга кичәсе саен 2шәр рәкәгать намаз укый торган була. Беркөнне ул хәзрәти Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмне төшендә күрә һәм Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Йә Әбү Мәлик! Син өммәтемә бүләкләр җибәрә торасың! Аллаһы Тәгалә сине гафу итте һәм сиңа җәннәттә Муниф исемле сарай хәзерләп куйды...» – дип, Әбү Мәликне шатландыра. Нинди генә изге эш эшләнмәсен, шуннан соң: «Әлхәмдү лилләһи раббиль-гъаләмин. Үәс-саләтү үәс-сәламү гъалә әшрафиль-мүрсәлинә сәй-йидинә. Мухәммәдин үә гъалә әлиһи үә әсхәби-һи әҗмәгыйн. Әлләһүммә әусыйль сәүәбә мә карәъту (әгәр Коръән укысаң, инде берәр эш эшләсәң, аның урынына «фәгъалту» диелер) илә рухи (шуннан соң мәетнең исемнәре әйтелер). Әмин», - дип дога кылсаң, бу эшнең саваплары мәетләрнең әрвахларына ирешер, инша Аллаһы.

*("Дин вә йола" газетасыннан)*

# Мөселманча сәламләшү

Сәлам бирү тәртибе түбәндәгеләр:

Аякта булган яисә йөргән кеше утырган кешегә сәлам бирер.

Аз кеше күп кешегә сәлам бирер, мәсәлән, урамда бердән артык кеше белән очрашсак, без алардан элек сәлам бирергә тиешбез.

Яшьләр картларга сәлам бирерләр, шулай ук картлар да яшьләрне сәламгә күндерер өчен беренче булып сәлам бирерләр.

Ике кеше урамда очрашканда, беренче булып сәлам бирүче өстенлек белән кабул ителер.

Байлыгы, нигъмәте вә малы күп булган кеше алданрак сәлам бирер. Мигъраҗ кичәсендә Мөхәммәд галәйһиссәләм Аллаһы белән очрашканда иң беренче булып Аллаһы Тәгалә сәлам биргән.

Бер кеше җәмәгатькә сәлам биреп, җәмәгатьтән берсе аның сәламен алса, башкаларның җавап бирүе кирәк түгел.

Динебез буенча түбәндәге хәлдә булган кешеләргә сәлам бирелмәс:

Намаз укып утырган кешегә.
Хөтбә укыган кешегә.
Коръән укып утырган кешегә.
Вәгазь сөйләгән имамга.
Коръән, хөтбә вә вәгазь тыңлаучыларга.
Азан укыган яисә камәт әйтүче мөәзингә.